**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясепоселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 27.06.2022** **№ 641**

**Башкарма комитетның «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Биектау муниципаль районы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы карарын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2021 елның 30 декабрендәге 1079 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру буенча чаралар хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 26 ноябрендәге 1136 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 16 апрелендәге 360 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Башкарма комитетның «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Биектау муниципаль районы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы карарын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2021 елның 30 декабрендәге 1079 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Билгеләргә:

максатчан билгеләнешкә ия булган субвенцияләр, субсидияләр, башка бюджетара трансфертлар рәвешендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан бирелгән бюджетара трансфертларның 2022 елның 1 гыйнварына торышына кулланылмаган өлеше 2022 елның беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетына кайтарылырга тиеш;

федераль башкарма хакимият органнарына Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләр тарафыннан тапшырыла торган бюджетара трансфертлардан файдалану турында хисаплар «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУ белән килештерелергә тиеш.»

- 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Билгеләргә:

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль казна учреждениеләре хезмәткәрләренә файдаланылмаган отпуск өчен акчалата

компенсация 2022 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль хакимиятенең тиешле органнарын, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль казна учреждениеләрен тотуга бюджет сметаларында хезмәт өчен түләүгә каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә башкарыла;

торгларда катнашучылар тарафыннан Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру конкурсында, аукционында катнашуга заявкаларны тәэмин итү буларак кертелә торган акча суммалары, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алуларда катнашучылар тарафыннан Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы исеменнән төзелгән дәүләт контрактлары үтәлешен тәэмин итү буларак кертелә торган акчалар Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы учреждениеләренең алар тарафыннан вакытлыча эш итүгә кергән акча белән операцияләрне исәпкә алу өчен аларның Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Биектау районы буенча Казначылык департаменты территориаль бүлекчәсендә үзләре ачкан шәхси счетларында исәпкә алына;

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджеты акчаларын алучылар Биектау муниципаль районы бюджеты исәбеннән билгеләнгән тәртиптә аларга җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга һәм хезмәтләр күрсәтүгә шартнамәләр (муниципаль контрактлары) төзегәндә түбәндәге аванс түләүләрен күздә тота:

шартнамә (дәүләт контракты) суммасының 100 процентына кадәр, әмма ирештерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларыннан артмаган күләмдә – басма матбугатка язылу һәм аларны сатып алу турындагы, элемтә, кабель һәм спутник телевидениесе хезмәтләре күрсәтү турындагы шартнамәләр (контрактлар) буенча, ягулык-майлау материаллары, транспорт чаралары, юлламалар, авиация һәм тимер юл, шәһәр һәм шәһәр яны транспортында йөрү өчен билетлар, ашыгыч кирәкле медикаментлар (кеше тормышына куркыныч янаган хәлләрдә кичектергесез медицина ярдәме күрсәтү өчен таләп ителә торган медикаментлар) сатып алуга шартнамәләр (контрактлар) буенча, квалификация күтәрү курсларында белем алу турындагы, яңадан һөнәри әзерлек узу турындагы, фәнни, методик, фәнни-гамәли һәм башка конференцияләрдә катнашу турындагы, проект документациясенә һәм инженерлык тикшеренүләренә дәүләт экспертизасын үткәрү турындагы, капиталь төзелеш объектларының смета кыйммәтен билгеләү дөреслеген тикшерү, аларны реконструкцияләү яки техник җиһазландыру турындагы шартнамәләр (муниципаль контрактлар) буенча, транспорт чаралары хуҗаларының граждан җаваплылыгын мәҗбүри иминләштерү шартнамәләре буенча, мәгълүмат белән тәэмин итү, пассажирлар йөртү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү турындагы шартнамәләр буенча, фәнни, мәдәни, экскурсия һәм спорт чараларын уздыруга шартнамәләр буенча, янгын сүндерү чараларын үткәрү турындагы шартнамәләр (муниципаль контрактлар) буенча, учреждение эшчәнлегенең уставта каралган төп төрләрен тәэмин итү максатларында товар-матди кыйммәтләр сатып алуга шартнамәләр (дәүләт контрактлары) буенча, яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) таралуга бәйле рәвештә, район территориясендә халыкның санитария-эпидемиологик иминлеген

тәэмин итү максатларында медицина әйберләре, медицина куллану материаллары, махсус кием, индивидуаль саклану чаралары һәм дару препаратлары сатып алуга шартнамәләр (муниципаль контрактлар) буенча;

шартнамә (муниципаль контракт) суммасының 90 процентыннан артмаган, әмма җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларыннан артмаган күләмдә – дару чаралары, медицина әйберләре, дәвалану туклануы буенча махсуслаштырылган продуктлары, дезинфекцияләү чаралары, иммунобиологик препаратлар белән тәэмин итү турындагы шартнамәләр (дәүләт контрактлары) буенча, әлеге пунктның бишенче абзацында каралган очраклардан тыш;

шартнамә (муниципаль контракт) суммасының 50 процентыннан артмаган, әмма ирештерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларыннан артмаган күләмдә – әгәр дә башкасы Россия Федерациясе законнарында каралмаган булса, калган шартнамәләр (муниципаль контрактлар) буенча.

юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш), индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү 2022 елда Россия Федерациясе Бюджет Кодексы нигезләмәләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджеты акчаларын алучылар «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 112 статьясындагы 65.1 өлеше нигезендә яклар килешүе буенча әлеге карар үз көченә кергәнче төзелгән шартнамәләргә (муниципаль контрактларга) алар тарафыннан каралган аванс түләүләре күләмнәрен «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 2021 елның 26 ноябрендәге 1136 номерлы карарының әлеге карар редакциясендәге 9 пункты белән билгеләнгән күләмнәргә кадәр, «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 96 статьясындагы 6 өлеше нигезендә билгеләнә торган шартнамәне (муниципаль контракт) үтәүне тәэмин итү күләмен үтәп, арттыру өлешендә үзгәрешләр кертергә хокуклы, дип билгеләргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2022 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Ф.Хисамутдинов